ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

15.03.2019 № 112

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының "Физик затлар милкенә салым турындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 6 пунктының 1 абзацына (икенче өлеш) туры китерү максатында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 19.11.2014 елның 82 № - лы «Физик затларның милкенә салым турында " гы карарына (12.10.2015 ел, № 7 һәм 15.01.2019, №108 карарлары редакциясендә, ) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә::

1.1. 1.2 пунктының 8 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым түләүченең салым ташламасына хокукын Раслау Салым Кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган шундый ук тәртип белән гамәлгә ашырыла.

Салым ташламаларын бирү турында гариза формасы һәм аны тутыру тәртибе, мондый гаризаны электрон формада тапшыру форматы салым һәм җыемнар

өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач һәм тиешле салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаганда закон көченә керә, 2019 нчы елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз тәэсирен бирә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес http://pravo.tatarstan.ru/ буенча, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:/ mendeleevsk.tatarstan.ru. адресы буенча халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева